ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2014 Казан ш. № 3-15/э

***Татарстан Республикасы халкы һәм кулланучыларның аңа тиңләнгән категорияләре өчен электр энергиясе бәяләренә (тарифларына) 2015 елгы түбәнәйтү коэффициентларын куллану турында***

“Электр энергетикасы турындагы” 26.03.2003 ел № 35-ФЗ федераль законына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Электр энергетикасындагы көйләүле бәяләр өлкәсендә бәяләр барлыкка килү турындагы” 29.12.2011 ел № 1178 карарына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәсенә ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР ИТӘ:

1. 2015 елның 1 январеннан 2015 елның 31 декабренә кадәр электр энергиясенә бәяләргә (тарифларга) түбәнәйтү коэффициентын 0,7 итеп билгеләргә:

1.1. шәһәр җирләрендә, билгеләнгән тәртиптә стационар ашамлык әзерләү электр плитәләре һәм (яки) электр белән җылыту корылмалары белән җиһазланган йортларда яшәүче Татарстан Республикасы халкы өчен;

1.2. авыл җирләрендә яшәүче Татарстан Республикасы халкы өчен.

2. 2015 елның 1 январеннан 2015 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы кулланучыларының халыкка тиңләнгән категорияләре өчен электр энергиясенә бәяләргә (тарифларга) шушы карарның кушымтасына ярашлы түбәнәйтү коэффициентлары кулланыла дип билгеләргә.

3. 2015 елның 1 январеннан 2015 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы кулланучыларының халыкка тиңләнгән, шушы карарга кушымтада күрсәтелмәгән категорияләре өчен электр энергиясенә бәяләргә 1гә тигез түбәнәйтү коэффициенты кулланыла дип билгеләргә.

4. Шушы карар аны рәсми игълан иткән көннән ун көн үткәч үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифларбуенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
12.12.2014 № 3-15/э
карарына кушымта

# Татарстан Республикасы кулланучыларының халыкка тиңләнгән категорияләре өчен электр энергиясенә бәяләргә (тарифларга) 2015 елгы түбәнәйтү коэффициентлары

| Т. № | Кулланучыларның халыкка тиңләнгән категорияләре | Түбәнәйтү коэффициентлары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2015-30.06.2015 | | 01.07.2015-31.12.2015 | |
| | | шәһәр җирләрендә билгеләнгән тәртиптә стационар ашамлык әзерләү электр плитәләре һәм (яки) электр белән җылыту җайланмалары белән җиһазланган биналарда урнашканнар өчен | авыл җирләрендә урнашканнар өчен | шәһәр җирләрендә билгеләнгән тәртиптә стационар ашамлык әзерләү электр плитәләре һәм (яки) электр белән җылыту җайланмалары белән җиһазланган биналарда урнашканнар өчен | авыл җирләрендә урнашканнар өчен |
| 1 | Гражданнарның коммерциясез бакчачылык яки дача берләшмәләре – гражданнар әгъзаларга бакчачылык һәм дача хуҗалыгындагы уртак социаль-хуҗалык мәсьәләләрен чишүдә булышу өчен оештырылган коммерциясез оешмалар | 0,7 | 0,7 | 0,7 | 0,7 |
| 2 | Электр энергиясен (егәрлеген) хөкем ителгәннәр тотыла торган биналарда шулар куллансын өчен алучы юридик затлар, шул биналар өчен электр энергиясен аерым исәпләү булган очракта | 0,7 | 0,7 | 0,9 | 0,9 |
| 3 | Гавам исәбенә асралучы дини оешмалар | 1 | 0,7 | 1 | 0,7 |
| 4 | Электр энергиясен (егәрлеген) арытаба халыкка һәм кулланучыларның аңа тиңләнгән | 0,7 | 0,7 | 1 | 1 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | категорияләренә халыкның һәм кулланучыларның аңа тиңләнгән категорияләренең факттагы кулланыш күләмнәрендә һәм тулай куллану урыннарында гражданнарның коммуналь-көнкүреш хаҗәтләренә кулланылган һәм коммерция (һөнәри) эшчәнлеге өчен кулланылмаган күләмнәрдә алучы гарантияләүче тәэминәтчеләр, энергия сатучы, энергия белән тәэмин итүче оешмалар | | | | |
| 5 | Электр энергиясен (егәрлеген) үзләренең хуҗалык корылмаларында (базларда, каралтыларда) куллану өчен алучы гражданнар берләшмәләре.<br>Электр энергиясен (егәрлеген) коммуналь-көнкүреш максатларында куллану өчен алучы һәм коммерция эшчәнлеге өчен кулланмаучы коммерциясез гражданнар берләшмәләре (гараж төзү, гараж кооперативлары) һәм аерым торган гаражларга ия гражданнар. | 1 | 0,7 | 1 | 0,7 |

Татарстан Республикасытарифларбуенча
Дәүләт комитеты, Тарифларбуенчакарарларны
кабул итү, оештурыһәмҗайга салу бүлеге